«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлегенең Апас шәһәр тибындагы поселогы халык җыены нәтиҗәләре һәм 2026 елда үзара салым кертү турында» 2025 елның “5” декабрендәге 2 номерлы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы
Апас шәһәр җирлеге Апас шәһәр тибындагы поселогының гражданнар җыенының карары

«Россия Федерациясе гавами хакимиятенең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлегенең Апас шәһәр тибындагы поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның, югарыда күрсәтелгән категориядәге гаилә әгъзаларының, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче һәм аларның гаилә әгъзалары тыш) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2026 елда үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү;

эшләрен башкарырга юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча 2025 елның 5 декабрендә Апас шәһәр җирлегенең Апас шәһәр тибындагы поселогы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 3716 кеше кертелгән, тавыш бирүдә кеше катнашкан гражданнар саны 1870 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 1870 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлегенең Апас шәһәр тибындагы поселогы халык җыенын узган дип, халык җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлегенең Апас шәһәр тибындагы поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның, югарыда күрсәтелгән категориядәге гаилә әгъзаларының, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче һәм аларның гаилә әгъзалары тыш) 500 (биш йөз) сум

күләмендә 2026 елда үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү;

эшләрен башкарырга юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районыны Апас шәһәр җирлегенең Апас шәһәр тибындагы поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән (көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, коляскада йөрүче инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның, югарыда күрсәтелгән категориядәге гаилә әгъзаларының, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче һәм аларның гаилә әгъзалары тыш) 500 (биш йөз) сум күләмендә 2026 елда үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү;
эшләрен башкарырга юнәлдерергә.

4. 2022 елга үзара салымның Апас шәһәр җирлеген су белән тәэмин итүгә каралган 64671,16 сум күләмендәге бер өлешен ремонтлауга, коймаларны коруга, традицион күмү урыннарын төзекләндерүгә юнәлтергә.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендындлары аша халыкка белдерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

“Апас шәһәр тибындагы бистәсе”
Муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары
Апас шәһәр җирлеге Советы Рәисе урынбасары Н.Т. Исмәгыйлев

Апас шәһәр тибындагы поселоклар муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары